КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.08.2019 г.Казань № 88-П

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия "Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар" мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында

"Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында"гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы федераль закон, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында"гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында, **боерам**:

1. Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия "Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар" мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия "Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар" мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (2нче кушымта)

3. Боерыкның үтәлүен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис

И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел_21.08_№_88-П___
боерыгына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия "Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар" мәдәни мирас объекты территориясе **чикләре**

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия "Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар" мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**картасы (схемасы)**



Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия “Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**картографик тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия “Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза

**Көнбатыш өлеше:** Говоров урамы буйлап (1-2 борылыш нокталары);
**Төньяк өлеше**: Ленин мәйданын кисеп чыгып, Говоров урамыннан Гассар урамына кадәр (2-3 борылыш нокталары);
**Көнчыгыш өлеше**: Гассар урамы буйлап (3-4 борылыш нокталары);
**Көньяк өлеше**: Казан урамы буйлап (4-1 борылыш нокталары).

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия “Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**борылыш нокталары**

| Нокта | Нокталарның җирле координатлар системасында координаты (МСК-16) | | Нокталарның 1984 елгы (WGS-84) Бөтендөнья геодезик координатлар системасында координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | x | y | Төньяк киңлек | Көнчыгыш озынлык |
| 1 | 472230.829 | 2301440.455 | 55°45'27.14206" | 52°03'17.14713" |
| 2 | 472266.701 | 2301298.975 | 55°45'28.30329" | 52°03'09.03514" |
| 3 | 472159.125 | 2301273.645 | 55°45'24.82512" | 52°03'07.58103" |
| 4 | 472127.754 | 2301418.387 | 55°45'23.80944" | 52°03'15.88051" |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел _21.08_ №_88-П__
боерыгына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Ленин мәйданы адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия “Икмәк мәйданы төзелеше, XVIII-XIX гасырлар” мәдәни мирас объекты территориясеннән
**файдалану режимы**

Җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

- законда билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектының физик сакланышын тәэмин итүгә һәм тарихи-мәдәни кыйммәтләрен саклауга юнәлдерелгән эшләр башкару, шул исәптә - консервация, ремонт, реставрация, заманча файдалану өчен җайлау;
- мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми һәм хәзерге шартларда мәдәни мирас объектының эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;
- мәдәни мирас объектының сак предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә, аны рөхсәт ителгән функциональ файдалану төрләре нигезендә заманча файдалану өчен җайлаштыру;
- мәдәни мирас объектының бөтенлеген бозучы вакытлы корылмаларны һәм объектларны сүтү;
- инженерлык инфраструктурасының гамәлдәге объектларын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) капиталь ремонтлау, шулай ук башкарыла торган эшләрнең мәдәни мирас объектына йогынтысы булмаган очракта (шул исәптән динамик йогынты), җир асты юлы белән инженерлык инфраструктурасының яңа объектларын төзү;
- мәдәни мирас объектын саклау, куллану һәм популярлаштыру максатында территорияне төзекләндерү; мәйданчыкларны, юлларны төзекләндерү өчен җыелма материалдан (таш, гранит, башка табигый һәм шулай ук имитацияләүче материаллардан) төрле катламнарны куллану, гамәлдәге юл өслеген ремонтлау, мәдәни мирас объектын яраклаштыру, аның тышкы күренешен һәм визуаль кабул ителешен бозмый торган капиталь булмаган корылмаларны урнаштыру.;
- аерым торган яктырту җиһазларын куллану, мәйдан периметры буенча навигация билгеләрен, юл билгеләрен урнаштыру;
- яшелләндерү: кыйммәтле агач токымнарын саклау, санитар кисү, яшелләндерүнең яңа элементларын утырту;

- тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау, кирәкле фәнни белешмәләр җитәрлек дәрәҗәдә булганда, мемориаль һәм архитектура-ансамбль мөнәсәбәтендә кыйммәтле булган югалган тарихи элементларны (биналар, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, коймалар, капкалар) торгызу;

-мәдәни мирас объектларының мәйдан (периметр) төзелешен формалаштыручы фасадларында беренче каттан да югары итмичә мәгълүмати кыр мәйданы 0,4 кв. метрдан артмаган язулар һәм билгеләмәләр урнаштыру.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр вәкаләтле орган тарафыннан мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр алып баруга бирелгән рөхсәт кәгазе нигезендә башкарыла.

Җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты территориялсе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела**:

- җир, төзелеш, мелиорация һәм башка эшләр башкару. Мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау эшләре искәрмә булып тора;

-капиталь төзелеш алып бару һәм һәйкәл территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм- киңлек характеристикаларын зурайту;

- мәдәни мирас объекты һәм аның янындагы территориясендә биналар (аларның фасадында һәм түбәләрендә) кондиционерлар, зур габаритлы антенналар һәм башка инженер җиһазлары элеементларын урнаштыру;

-тышкы реклама чараларын урнаштыру;

--инженер инфраструктурасы объектларын (су, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, канализация, телефонлаштыру челтәрләрен) җир өстеннән үткәрү;

-- мәдәни мирас объектына һәм аның әйләнә-тирәлеге төзелешенә динамик йогынты ясый торган технологияләрне куллану; мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы көнкүреш калдыклары белән чүпләү.